КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 14 декабрь г.Казань № 1230

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзелеш өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формаларын раслау хакында» 2018 ел, 19 апрель, 268 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзелеш өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формаларын раслау хакында» 2018 ел, 19 апрель, 268 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 15 апрель, 285 нче; 2019 ел, 24 май, 435 нче; 2019 ел, 22 июль, 614 нче; 2020 ел, 17 март, 195 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формаларын раслау хакында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап формасын;

җирле үзидарә органнары тарафыннан торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап формасын.»;

җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап формасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

җирле үзидарә органнары тарафыннан торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап формасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 14 декабрь, 1230 нчы
карары белән расланды

Форма

_______ елның _____ кварталына

______________________________________________
(муниципаль берәмлек исеме)

жирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) кучемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткеч зурлыгы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итеп, муниципаль берәмлек территориясендә төзелә (булдырыла) торган күпфатирлы йортлар һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектлары (алга таба – объектлар) саны | |
| 2. | Законнарның бозылуы ачыкланган объектлар саны | |
| 3. | Өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итеп, муниципаль берәмлек территориясендә төзелә торган объектлар турында белешмә | бу хисапның кушымтасы нигезендә |
| 4. | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Йорт төзүчеләр тарафыннан күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән шартнамәләр, төзелеш проектының җыелма тупланма ведомосте буенча төзелеш проектларын гамәлгә ашыруның якынча графикларын һәм үз йөкләмәләрен үтәү турында контрольдә тоту органына хисаплылык бирү формаларын һәм тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 октябрендәге 656/пр номерлы боерыгында билгеләнгән форма буенча квартал хисапларын биргән йорт төзүчеләр саны | |
| 5. | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Йорт төзүчеләр тарафыннан күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | турында, шул исәптән шартнамәләр, төзелеш проектының җыелма тупланма ведомосте буенча төзелеш проектларын гамәлгә ашыруның якынча графикларын һәм үз йөкләмәләрен үтәү турында контрольдә тоту органына хисаплылык бирү формаларын һәм тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 октябрендәге 656/пр номерлы боерыгында билгеләнгән форма буенча квартал хисапларын бирмәгән йорт төзүчеләр саны | |
| 6. | «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 статьясында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, йорт төзүчеләр тарафыннан күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын әлеге акчаны эскроу счетларында урнаштыру юлы белән җәлеп итүче йорт төзүчеләр саны | |
| 7. | Муниципаль берәмлек территориясендә өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүче йорт төзүчеләр саны | |
| 8. | Суд карары белән бурычларын түләргә хәле җитмәгәннәр (банкротлар) дип танылган йорт төзүчеләр саны | |
| 9. | Өлешле төзелеш өлкәсендә ачыкланган закон бозулар саны | |
| 10. | 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законны бозуга бәйле мөрәҗәгатьләр саны, шул исәптән:<br>гражданнардан;<br>юридик затлардан | |
| 11. | Җирле үзидарә органнарының өлешле төзелештә катнашучылар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өчен гаризалар белән судка мөрәҗәгатьләре саны | |
| 12. | Өлешле төзелештә катнашучылар файдасына канәгатьләндерелгән дәгъвалар саны | |
| 13. | Җинаять эшләрен кузгалту турында мәсьәләләрне хәл итү өчен федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында билгеләнгән, җинаять җәзасы бирелә торган гамәлләр кылу билгеләренә ия таләпләрне бозу фактлары ачыклануга бәйле булган, хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар саны | |
| 14. | Җинаять эшләрен кузгалту турында мәсьәләләрне хәл итү өчен җирле үз идарә органнары тарафыннан җинаять җәзасы бирелә торган гамәлләр кылу билгеләренә ия мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары ачыклануга бәйле җибәрелгән | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | материаллар буенча хокук саклау органнары тарафыннан кузгатылган җинаять эшләре саны | |
| 15. | Җирле үзидарә органы тарафыннан йорт төзүчеләргә җибәрелгән закон бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр саны | |
| 16. | Җирле үзидарә органы тарафыннан йорт төзүчеләргә җибәрелгән законнарны бозуларны бетерү турында үтәлгән күрсәтмәләр саны | |
| 17. | Законнарда билгеләнгән җаваплылыкка тартылган йорт төзүчеләр (аларның вазыйфаи затлары) саны | |
| 18. | Җирле үзидарә органнарының йорт төзүче тарафыннан өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлек гамәлгә ашырылуны билгеле бер срокка туктатып тору турындагы гариза белән арбитраж судка мөрәҗәгатьләре саны, шул исәптән билгеле бер срокка кадәр эшчәнлекләре туктатып торылган йорт төзүчеләр саны | |
| 19. | 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда, җирле үзидарә органнарының арбитраж судка йорт төзүчене бетерү турындагы гариза белән мөрәҗәгатьләре саны, шул исәптән суд карары нигезендә бетерелгән йорт төзүчеләр саны | |
| 20. | Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү кысаларында үткәрелгән чаралар саны (контрольдә тотыла торган зат белән үзара хезмәттәшлек итмичә) | |
| 21. | 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.3 статьясындагы 5, $6^2$ өлешләре нигезендә торак төзелеше буенча бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылган документлар саны | |
| 22. | «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз рәсми сайтларында йорт төзүчеләрнең эшчәнлегенә карата үткәрелгән тикшерүләр турында урнаштырылган мәгълүмат (Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалану мөмкинлеге чикләнгән белешмәләрдән тыш) саны, шулай ук 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның һәм башка мәҗбүри таләпләрне бозган өчен йорт төзүчене, аның вазифаи затларын административ җаваплылыкка тарту турында закон көченә кергән карарлар турында белешмә урнаштыру | |

Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисапка кушымта

Форма

_______ елның ___ кварталына

_______________________________________________,

(муниципаль берәмлек исеме)

## өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итеп, муниципаль берәмлек территориясендә төзелә торган объектлар турында белешмә

| Т/с | Йорт төзүче юридик затның – тулы һәм кыскартылган исеме, урнашу урыны, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган, төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН), дәүләт теркәвенә алу датасы, салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры/салым органында исәпкә кую сәбәбе коды (алга таба ИНН/КПП), йорт төзүченең рәсми сайты | Күчемсез мөлкәт объекты исеме (функциональ билгеләнеше, катлар саны), күчемсез мөлкәт объектының урнашу урыны (төзелеш адресы) | Күчемсез мөлкәт объектын төзү (булдыру) өчен бирелгән җир кишәрлегенә хокук турында мәгълүмат, җир кишәрлегенең кадастр номеры, хокук төре (милек, аренда, субаренда, чикләнмәгән вакытта файдалану), аренда шартнамәсенең датасы, номеры, аның гамәлдә булу чоры, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында җир кишәрлегенә хокукны теркәү датасы һәм номеры | Төзелешкә рөхсәт кәгазе бирү турында мәгълүмат (төзелешкә рөхсәт кәгазе номеры һәм аны бирү датасы, төзелешкә рөхсәт кәгазе биргән орган (оешма) исеме, төзелешкә рөхсәт кәгазе гамәленең башлангыч срогы), төзелешкә рөхсәт кәгазенә үзгәрешләр кертү датасы, кертелгән үзгәрешләрнең кыскача тасвирламасы, төзелешкә рөхсәт кәгазе гамәле срогын озынайту турында мәгълүмат, төзелешкә рөхсәт кәгазе гамәленең яңа срогы, Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылган проект декларациясе нигезендә объектны эксплуатацияләүгә тапшыруга рөхсәт кәгазе алуның планлаштырыла торган сроклары | Объектның гомуми мәйданы, шул исәптән торак | Йорт төзүченең һәм проект декларациясенең өлешле төзелеш турындагы законнар таләпләренә туры килүе турында бәяләмә алган датага карата проект декларациясендә күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объекты төзүнең (булдыруның) планлаштырыла торган кыйммәте, млн.сум. | Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында бирелгән проект декларациясе номеры | Күчемсез мөлкәт объекты составында өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре (алга таба – өлешле катнашу шартнамәсе) төзелә алган мөстәкыйль өлешләрнең гомуми саны һәм мәйданы, шул исәптән: | | | | | | Өлешле төзелештә катнашучыларның күчемсез мөлкәт объектын төзүгә (булдыруга) җәлеп ителгән акча суммасы турында мәгълүмат* | | Йорт төзүченең исәп-хисап счеты ачылган вәкаләтле банк | | Өлешле төзелештә катнашучыларның эскроу счетлары ачылырга тиешле банк * | | Өлешле төзелеш объектлары буенча төзелгән өлешле катнашу шартнамәләре турында мәгълүмат | | | Йорт төзүче тарафыннан өлешле катнашу шартнамәсенең үтәлеше турында мәгълүмат | | Өлешле төзелеш объектларын өлешле төзелештә катнашучыларга тапшыруның беренче срогы | Өлешле төзелеш объектларын өлешле төзелештә катнашучыларга тапшыруның планлаштырыла торган срогы | Төзелеп беткән күчемсез мөлкәт объектын эксплуатацияләүгә тапшыруга рөхсәт бирү кәгазе турында мәгълүмат (номеры, тапшыру датасы, объектны эксплуатацияләүгә тапшыруга рөхсәт кәгазе биргән орган исеме) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | торак урыннар | | торак булмаган урыннар | | машина урыннары | | хисап чорында өлешле төзелештә катнашучыларның җәлеп ителгән акча суммасы, млн.сум | йорт төзүчеләр тарафыннан өлешле төзелештә катнашучыларның күчемсез мөлкәт объектын төзүгә (җәлеп итүгә) җәлеп ителгән акчасының гомуми суммасы, млн.сум | йорт төзүченең исәп-хисап счеты ачылган вәкаләтле органның оештыру-хокук формасы һәм исеме (вәкаләтле органның кыскартылган исеме) | вәкаләтле банкта йорт төзүченең исәп-хисап счеты реквизитлары (исәп-хисап счеты номеры, корреспондентлык счеты, БИК, ИНН/ КПП, ОГРН, ОКПО) | өлешле төзелештә катнашучыларның эскроу счетлары ачылырга тиешле кредит оешмасының оештыру-хокук формасы һәм тулы исеме | өлешле төзелештә катнашучыларның эскроу счетлары ачылырга тиешле кредит оешмасы өчен салым түләүченең индивидуаль номеры | беренче өлешле катнашу шартнамәсен төзү датасы | хисап чорының соңгы календарь датасына төзелгән һәм гамәлдә булган өлешле катнашу шартнамәсенең гомуми саны | өлешле катнашу шартнамәсе буенча йөкләмәләрнең гомуми суммасы, млн. сум | йорт төзүче тарафыннан үтәлгән өлешле катнашу шартнамәсе саны, данә | йорт төзүче тарафыннан үтәлмәгән өлешле катнашу шартнамәсе саны, данә | | | |
| | | | | | | | | саны, данә | мәйданы, кв.метр | саны, данә | мәйданы, кв.метр | саны, данә | мәйданы, кв.метр | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

*Йорт төзүче тарафыннан өлешле төзелештә катнашучыларның акчасы компенсация фондына күчереп җәлеп ителгән очракта, тутырылмый.

_______________________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 14 декабрь, 1230 нчы
карары белән расланды

Форма

_______ елның ___ кварталына

________________________________________________
(муниципаль берәмлек исеме)

жирле үзидарә органнары тарафыннан торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап

| Т/с | Күрсәткеч | Хисап мәгълүматы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Муниципаль берәмлек территориясендә торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан төзелә (булдырыла) торган күпфатирлы йортлар саны | |
| 2. | Законнарның бозылуы ачыкланган күпфатирлы йортлар саны | |
| 3. | Муниципаль берәмлек территориясендә торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан төзелә торган күпфатирлы йортлар турында белешмә | бу хисапның кушымтасы нигезендә |
| 4. | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчасын җәлеп итүгә бәйле торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында, шул исәптән мондый кооперативның кооператив әгъзалары һәм башка затлар алдында үз йөкләмәләрен башкару турында хисаплылык формасын һәм торак-төзелеш кооперативы тарафыннан әлеге хисаплылыкны Россия Федерациясе субъектының күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы башкарма хакимияте органына бирү тәртибен раслау хакында» 2017 елның 3 июлендәге № 955/пр номерлы боерыгында билгеләнгән форма буенча квартал хисаплылыгын үз вакытында тапшырган торак-төзелеш кооперативлары саны | |
| 5. | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчасын җәлеп итүгә | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | бәйле торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында, шул исәптән мондый кооперативның кооператив әгъзалары һәм башка затлар алдында үз йөкләмәләрен башкару турында хисаплылык формасын һәм торак-төзелеш кооперативы тарафыннан әлеге хисаплылыкны Россия Федерациясе субъектының күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы башкарма хакимияте органына бирү тәртибен раслау хакында» 2017 елның 3 июлендәге № 955/пр номерлы боерыгында билгеләнгән форма буенча квартал хисаплылыгын үз вакытында тапшырмаган торак-төзелеш кооперативлары саны | |
| 6. | Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчасын җәлеп итүче торак-төзелеш кооперативлары саны | |
| 7. | Суд карары белән бурычларын түләргә хәле җитмәгәннәр (банкротлар) дип танылган йорт төзүчеләр саны | |
| 8. | Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясындагы 3 өлешендә (алга таба күпфатирлы йортны карап тотудан тыш) һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясында каралган мәҗбүри таләпләр бозылуга бәйле мөрәҗәгатьләр саны, шул исәптән:<br>гражданнардан;<br>юридик затлардан | |
| 9. | Җирле үзидарә органнарының торак-төзелеш кооперативлары әгъзалары хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өчен гаризалар белән судка мөрәҗәгатьләре саны | |
| 10. | Торак-төзелеш кооперативы әгъзалары файдасына канәгатьләндерелгән дәгъвалар саны | |
| 11. | Җинаять эшләре ачу турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен җинаять җәзасына тартыла торган гамәлләр билгеләренә ия мәҗбүри таләпләрне бозу фактларын ачыклауга бәйле булган, хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар саны | |
| 12. | Җинаять эшләрен кузгалту турында мәсьәләләрне хәл итү өчен җирле үз идарә органнары тарафыннан җинаять җәзасы бирелә торган гамәлләр кылу билгеләренә ия мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары ачыклануга бәйле җибәрелгән материаллар буенча хокук саклау органнары тарафыннан кузгатылган җинаять эшләре саны | |
| 13. | Җирле үзидарә органы тарафыннан торак-төзелеш кооперативларына җибәрелгән закон бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр саны | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 14. | Җирле үзидарә органы тарафыннан торак-төзелеш кооперативларының идарә итү органнарына җибәрелгән законнарны бозуларны бетерү турында үтәлгән күрсәтмәләр саны | |
| 15. | Законнарда билгеләнгән җаваплылыкка тартылган торак-төзелеш кооперативлары (аларның вазыйфаи затлары) саны | |
| 16. | «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз рәсми сайтында торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә карата үткәрелгән тикшерүләр турында урнаштырылган мәгълүмат (Россия Федерациясе законнары нигезендә кулланылышы чикләнгән белешмәдән тыш) саны, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләрен һәм башка мәҗбүри таләпләрне бозган өчен торак-төзелеш кооперативын административ җаваплылыкка тарту турында белешмә урнаштыру | |